КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 2 март г.Казань № 6-456

«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 ел, 21 ноябрь, ФЗ-323 нче Федераль законның 12 статьясы, Россия Федерациясенең Оборона министры һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләүне медицина ягыннан тәэмин итүне оештыру турында» 2001 ел, 23 май, 240/168 нче боерыгы нигезендә:

1. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының муниципаль берәмлекләр буенча бүлекләре белән үзара хезмәттәшлек итеп:

2020 елның апреле – маенда Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче 2004 – 2005 елларда туган ир җенесендәге Россия Федерациясе гражданнарына (алга таба – яшүсмерләр) медицина оешмалары җитәкчеләре раслаган һәм мәгариф оешмалары җитәкчеләре белән килештерелгән графиклар нигезендә планлы профилактика медицина тикшерүләре үткәрергә;

билгеләнгән медицина документларын рәсмиләштереп, яшүсмерләргә планлы профилактика медицина тикшерүләрен һәм тиешле дәвалау-сәламәтләндерү чараларын үз вакытында, тулысынча һәм сыйфатлы үткәрүне тәэмин итәргә;

планлы профилактика медицина тикшерүләрен үткән һәм планлы профилактика медицина тикшерүен үтәргә килмәгән яшүсмерләр исемлекләрен Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының муниципаль берәмлекләр буенча бүлекләренә кертергә;

2020 елның 25 июленә кадәр 2020 елда яшүсмерләрне беренчел хәрби исәпкә куйганга кадәр аларга планлы профилактика медицина тикшерүләрен үткәрүгә йомгаклар ясарга һәм профилактика медицина тикшерүләрен, дәвалау-сәламәтләндерү чараларын үткәрү нәтиҗәләре турындагы аналитик белешмәләрне һәм мәгълүматларны (абсолют саннарда) Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына кертергә;

2020 елның 20 августына кадәр 2020 елда яшүсмерләргә аларны беренчел хәрби исәпкә куйганга кадәр медицина ягыннан тәэмин итү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

2. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

яшүсмерләрне хәрби хезмәткә әзерләү буенча дәвалау-сәламәтләндерү чаралары планнарын раслауны;

мәгариф оешмаларында яшүсмерләргә мәгариф оешмалары һәм дәүләт медицина оешмалары җитәкчеләре раслаган графиклар нигезендә планлы профилактика медицина тикшерүләре үткәрү өчен шартлар тудыруны тәэмин итүне.

3. Бу боерыкка теркәлгән 2004 – 2005 елларда туган яшүсмерләргә аларны беренчел хәрби исәпкә куйганга кадәр планлы профилактика медицина тикшерүләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы медицина оешмалары исемлеген расларга.

4. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 2 март, б-456 нчы
боерыгы белән расланды

2004 – 2005 елларда туган яшүсмерләрне беренчел хәрби исәпкә куйганга кадәр медицина ярдәме белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләре исемлеге

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (алга таба – ДАССУ);

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» ДАССУ;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» ДАССУ;

«Республика туберкулезга каршы клиник диспансеры» ДАССУ;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика наркология диспансеры» ДАССУ;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Профессор Е.В.Адамюк исемендәге Республика клиник офтальмология хастаханәсе» ДАССУ;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Академик В.М.Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе» ДАССУ;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының СПИДны һәм йогышлы авыруларны профилактикалау һәм аларга каршы көрәш буенча республика үзәге» ДАССУ;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика стоматология поликлиникасы» ДАССУ;

«Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе» ДАССУ;

«Республика клиник тире-венерология диспансеры» ДАССУ;

«Казан эндокринология диспансеры» ДАССУ;

«Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;

«Азнакай үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;

«Аксубай үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;

«Актаныш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;

«Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;

«Әлки муниципаль районының Базарлы Матак үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;

«Перинаталь үзәк белән Әлмәт балалар шәһәр хастаханәсе» ДАССУ;

«Апас үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;

«Арча үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;

«Әтнә үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Балтач үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Бөгелмә үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Буа үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Югары Ослан үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Биектау үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Чүпрәле үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Зәй үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Кайбыч үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Кама Тамагы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Кукмара үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Лаеш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Лениногорск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Менделеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Минзәлә үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Мөслим үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
Түбән Кама шәһәренең «Перинаталь үзәк белән балалар шәһәр хастаханәсе» ДАССУ;
«Кама Аланы район хастаханәсе» ДАССУ;
«Яңа Чишмә үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Нурлат үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Питрәч үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Саба үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Сарман үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Спас үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Тәтеш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Тукай үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Теләче үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Чирмешән үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Чистай үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;
«Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» Татарстан Республикасы ДАССУ;
«Яр Чаллы йогышлы авырулар хастаханәсе» ДАССУ;
«Кама балалар медицина үзәге» ДАССУ;
«2 нче балалар шәһәр поликлиникасы» ДАССУ (Яр Чаллы шәһәре);
«3 нче балалар шәһәр поликлиникасы» ДАССУ (Яр Чаллы шәһәре);
«Ф.Г.Әхмәрова исемендәге 4 нче балалар шәһәр поликлиникасы» ДАССУ (Яр Чаллы шәһәре);
«5 нче балалар шәһәр поликлиникасы» ДАССУ (Яр Чаллы шәһәре);

«6 нчы балалар шәһәр поликлиникасы» ДАССУ (Яр Чаллы шәһәре);
Казан шәһәренең «1 нче балалар шәһәр поликлиникасы» ДАССУ;
Казан шәһәренең «7 нче балалар шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУ;
Казан шәһәренең «8 нче шәһәр балалар хастаханәсе» ДАССУ;
Казан шәһәренең «2 нче балалар шәһәр поликлиникасы» ДАССУ;
Казан шәһәренең «4 нче балалар шәһәр поликлиникасы» ДАССУ;
Казан шәһәренең «6 нчы шәһәр балалар поликлиникасы» ДАССУ;
Казан шәһәренең «7 нче шәһәр балалар поликлиникасы» ДАССУ;
Казан шәһәренең «9 нчы шәһәр балалар поликлиникасы» ДАССУ;
Казан шәһәренең «10 нчы шәһәр балалар поликлиникасы» ДАССУ;
Казан шәһәренең «11 нче шәһәр балалар поликлиникасы» ДАССУ.
Казан шәһәренең «8 нче шәһәр поликлиникасы» ДАССУ;
Казан шәһәренең «18 нче үзәк шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУ;
югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең медик-санитар часте;
Казан шәһәренең «Медицина университеты клиникасы» ДАССУ.